**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 1** **30.01.2015 ел**

**Савруш авыл җирлеге Советы Башлыгы**
**2014 ел өчен һәм 2015 елга фаразлар турында**
**социаль-икътисади үсеш йомгаклары буенча Хисабы**

Савруш авыл җирлеге башлыгының 2014 елда җирлекнең социаль – икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2015 елга фаразлар буенча хисабын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң. 2013 елда авыл җирлеге Советы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 6.10.2003 ел, №131-ФЗ законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә, Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлеге Советы КАРАРы

1. Савруш авыл җирлеге башлыгы Кузьмин Андрей Георгиевичның хисабы. авыл җирлегенең 2013 елдагы социаль – икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2014 елга фаразны игътибарга алырга.
2. 2014 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсешенең төп бурычы- халыкның тормыш сыйфатын үстерүне тәэмин итү.
3.Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә:
1. Яшьләрне авылга беркетү өчен кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә тормышка ашырыла торган программалар мөмкинлекләреннән файдаланырга.
2. Халыкның тормыш дәрәҗәсен киметмәү һәм гражданнарның социаль хезмәтләрдән тигез файдалануын тәэмин итү буенча чаралар күрү.
3. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү һәм гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм абруен ныграк яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
4. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү чараларын дәвам итү.
5. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында әйтелгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
6. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм фикер алышканда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне гомумиләштерергә.
7. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Савруш авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Савруш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /А.Г. Кузьмин/